**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «НИЖНЕЧЕРШИЛИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» ЛЕНИНОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «ТҮБӘН ЧЫРШЫЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 елның 20 декабре № 51

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Түбән Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2012 елның 24 декабрендәге 14 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Түбән Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә яшәүче яки килүче гражданнарны беренчел хәрби исәпкә алу» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законга туры китерү максатыннан, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының “Түбән Чыршылы авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Түбән Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2012 елның 24 декабрендәге 14 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Түбән Чыршылы авыл

җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә яшәүче яки килүче гражданнарны беренчел хәрби исәпкә алу» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

5 бүлектә:

5.1 пунктының 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) мөрәҗәгать итүчедән документлар яисә мәгълүмат алу яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, Лениногорск муниципаль районының муниципаль хокукый актларында каралмаган гамәлләрне башкару талап итү»;

түбәндәге эчтәлекле 5.7.1 пунктын өстәргә:

«5.7.1 Шикаятьне әлеге бүлекнең 5.7 өлешендә күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчегә җавапта канәгатьләндерелергә тиешле дип тану очрагында, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган, күпфункцияле үзәк яисә «дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законның 16 статьясындагы 111 өлешендә каралган оешма тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәткәндә ачыкланган бозуларны кичекмәстән бетерү максатларында гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук бирелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенәләр һәм мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү максатларында башкарырга кирәк гамәлләр турында мәгълүмат бирелә.»

2. Әлеге карарны Лениногорск районы, Зәй - Каратай авылы территориясе буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
«Лениногорск муниципаль районы»
«Түбән Чыршылы авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге
башкарма комитеты
җитәкчесе Н.Я. Хәйруллина